КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 30 март г.Казань № 247

Татарстан Республикасы сәнәгате өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына Татарстан Республикасының дәүләт сәнәгатьне үстерү фондлары өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан керә торган акча исәбеннән финанс ярдәме күрсәтүне гамәлгә ашыру эффективлыгының максатчан күрсәткечләрен билгеләү тәртибен раслау турында

«Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте турында» 2016 ел, 21 апрель, ТРЗ-24 нче Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 өлешнең 9 нчы пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы сәнәгате өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына Татарстан Республикасының дәүләт сәнәгатьне үстерү фондлары өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан керә торган акча исәбеннән финанс ярдәме күрсәтүне гамәлгә ашыру эффективлыгының максатчан күрсәткечләрен билгеләү тәртибен расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 30 март, 247 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы сәнәгате өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына Татарстан Республикасының дәүләт сәнәгатьне үстерү фондлары өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан керә торган акча исәбеннән финанс ярдәме күрсәтүне гамәлгә ашыру эффективлыгының максатчан күрсәткечләрен билгеләү тәртибе

I. Гомуми нигезләмәләр

1. Бу Тәртип «Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте турында» 2016 ел, 21 апрель, ТРЗ-24 нче Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы сәнәгате өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына Татарстан Республикасының дәүләт сәнәгатьне үстерү фондлары өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан керә торган акча исәбеннән финанс ярдәме күрсәтүне гамәлгә ашыру эффективлыгын бәяләүне (алга таба – финанс ярдәме күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеген бәяләү) үткәрү кагыйдәләрен билгели.

2. Финанс ярдәме күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру эффективлыгын бәяләү дәүләт ярдәме чараларын оптимальләштерү максатларында үткәрелә.

3. Сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына финанс ярдәме (алга таба – финанс ярдәме) дәүләт сәнәгатьне үстерү фондлары тарафыннан «Россия Федерациясендә сәнәгать сәясәте турында» 2014 ел, 31 декабрь, ФЗ-488 нче Федераль законның 11 статьясындагы 4 өлеш нигезендә каралган формаларда күрсәтелә.

4. Финанс ярдәме күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру эффективлыгын бәяләү финанс ярдәме күрсәтү чараларыннан файдалану эффективлыгын бәяләүнең төп принциплары һәм аның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре нигезендә үткәрелә.

5. Финанс ярдәме күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру эффективлыгын бәяләү ел саен үткән финанс елы өчен (алга таба – хисап елы) финанс ярдәме күрсәтүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт сәнәгатьне үстерү фонды тарафыннан үткәрелә.

II. Финанс ярдәме күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру эффективлыгын бәяләүнең төп принциплары

6. Финанс ярдәме күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру эффективлыгын бәяләүнең төп принциплары түбәндәгеләр була:

а) финанс ярдәме күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру буенча фактта ирешелгән һәм планлаштырылган (фаразланган) нәтиҗәләрнең әлеге чараларны күрсәтү максатларына туры килү дәрәҗәсен исәпкә алу;

б) дәүләт ярдәме күрсәтү максатларын һәм бурычларын билгели торган финанс ярдәме күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә эзлекле ирешү өстенлеген исәпкә алу.

## III. Финанс ярдәме күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру эффективлыгын бәяләү

7. Хисап елы йомгаклары буенча финанс ярдәме чараларын гамәлгә ашыру эффективлыгын бәяләү, Татарстан Республикасының дәүләт сәнәгатьне үстерү фонды һәм финанс ярдәменнән файдаланучылар белән төзелә торган килешүләрдә (шартнамәләрдә) (алга таба – килешү) билгеләнгән план буенча күрсәткечләргә ирешүдән чыгып, финанс ярдәме чараларын гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеге күрсәткечләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

Дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары эффективлыгын бәяләү өчен түбәндәгеләр кулланыла:

1) финанс ярдәме күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеге күрсәткече, ул финанс ярдәме күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру нәтиҗәләренең уртача арифметик бәяләре буларак билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$PP = \frac{\sum_{i=1}^{N} OP_i}{N},$$

монда:

PP – финанс ярдәме күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеге күрсәткече;

$OP_i$ – финанс ярдәме күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру нәтиҗәсенең бәясе;

N – финанс ярдәме күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеге күрсәткечләре саны.

Финанс ярдәме күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру нәтиҗәсенең бәясе ($OP_i$) финанс ярдәме күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру нәтиҗәләренең 1 проценты өчен 1 балл (Pi), әмма иң күбе 100 балл исәпләүдән чыгып билгеләнә.

Финанс ярдәме күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру нәтиҗәсе ($P_i$) түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$P_i = \frac{i_{факт}}{i_{план}} \cdot 100,$$

монда:

$i_{факт}$ – финанс ярдәме күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеге i-күрсәткеченең фактта ирешелгән мәгънәсе;

$i_{план}$ – финанс ярдәме чараларын гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеге i-күрсәткеченең план буенча мәгънәсе;

2) хисап елы өчен финанс ярдәме күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеге һәм файдаланылган ресурслар арасындагы бәйләнешне билгели

торган финанс ярдәме күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру эффективлыгы түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$E = \frac{PP}{\frac{F_{факт}}{F_{план}}},$$

монда:

E – финанс ярдәме күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру эффективлыгы;

PP – финанс ярдәме күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеге;

$F_{план}$ – хисап елына финанс ярдәме күрсәтүнең план буенча суммасы;

$F_{факт}$ – хисап елында финанс ярдәме күрсәтүнең фактта күчерелгән суммасы.

## IV. Финанс ярдәме күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру эффективлыгын бәяләүне үткәрүне оештыру

8. Хисап елында финанс ярдәме күрсәткән Татарстан Республикасы дәүләт сәнәгатьне үстерү фонды агымдагы финанс елының 1 маена кадәр финанс ярдәме күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү турындагы хисапларны аларны файдаланучылардан килешүләрдә билгеләнгән формалар буенча җыюны гамәлгә ашыра.

9. Хисап елында финанс ярдәме күрсәткән Татарстан Республикасы дәүләт сәнәгатьне үстерү фонды тарафыннан бу Тәртипнең III бүлеге нигезендә финанс ярдәме күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру эффективлыгын бәяләү үткәрелә.

10. Финанс ярдәме күрсәтүне файдаланучылар яктылыгында финанс ярдәме күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру эффективлыгын бәяләү нәтиҗәләре турында мәгълүматлар бу Тәртипкә теркәлгән кушымта нигезендә фомалаштырыла.

Финанс ярдәме күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру эффективлыгын бәяләү нәтиҗәләре турындагы мәгълүматларның тулылыгы һәм дөреслеге өчен Татарстан Республикасы дәүләт сәнәгатьне үстерү фонды җавап бирә.

11. Финанс ярдәме күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру эффективлыгын бәяләү нәтиҗәләре турындагы мәгълүматлар агымдагы финанс елының 1 июненә кадәр Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына җибәрелә.

12. Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары эффективлыгын бәяләү нәтиҗәләрен гомумиләштерүне гамәлгә ашыра һәм агымдагы финанс елының 1 августына кадәр Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча хисап елы өчен финанс ярдәме күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру эффективлыгын бәяләү нәтиҗәләре турындагы җыелма хисапны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертә.

Татарстан Республикасы сәнәгате өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына Татарстан Республикасының дәүләт сәнәгатьне үстерү фондлары өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан кирә торган акча исәбеннән финанс ярдәме күрсәтүне гамәлгә ашыру эффективлыгының максатчан күрсәткечләрен билгеләү тәртибенә
кушымта

Форма

20___ ел өчен
финанс ярдәме күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру эффективлыгын бәяләү нәтиҗәләре турында мәгълүматлар

Финанс ярдәме күрсәтү чарасының исеме ______________________________

Финанс ярдәме күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру нәтиҗәләлегә күрсәткечләренең гомуми саны ______________________________

Җаваплы үтәүче турында мәгълүматлар:
Ф.И.Ат.ис.:
______________________________
Вазыйфасы: ______________________________
Телефоны: ______________ Электрон почтасы: ______________________________

<table>
<tr><td rowspan="3">Т/с</td><td rowspan="3">Файдаланучылар</td><td colspan="5">Финанс ярдәме күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеге</td><td colspan="3">Финанс ярдәме чараларын гамәлгә ашыру эффективлыгы</td></tr>
<tr><td colspan="2">Финанс ярдәме күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеге күрсәткече исеме (i) [1]</td><td rowspan="2">Финанс ярдәме күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру нәтиҗәсе, % $(P_i = \frac{i_{факт}}{i_{план}} \cdot 100)$</td><td rowspan="2">Финанс ярдәме күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру нәтиҗәсенең бәясе, балл $(OP_i \le 100)$</td><td rowspan="2">Финанс ярдәме күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеге, балл $\left(PP = \frac{\sum_{i=1}^{N} OP_i}{N}\right)$</td><td rowspan="2">Финанс ярдәме күрсәтүнең план буенча суммасы, мең сум (Fплан)</td><td rowspan="2">Финанс ярдәме күрсәтүнең фактта күчерелгән суммасы, мең сум ($F_{факт}$)</td><td rowspan="2">Финанс ярдәме күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру эффективлыгы, балл $(E = \frac{PP}{\frac{F_{факт}}{F_{план}}})$</td></tr>
<tr><td>План буенча мәгънәсе, үлчәү берәмлеге ($i_{план}$)</td><td>Факттагы мәгънәсе, үлчәү берәмлеге ($i_{факт}$)</td></tr>
<tr><td>1</td><td>2</td><td>3</td><td>4</td><td>5</td><td>6</td><td>7</td><td>8</td><td>9</td><td>10</td></tr>
<tr><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td colspan="2">Барлыгы</td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
</table>

[1] Мәгълүматлар финанс ярдәме күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру нәтиҗәлелегенең һәр күрсәткече буенча бирелә.